Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Каенсар авыл җирлеге Советы

Карар

23 ноябрь 2021ел №28

«Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы белән идарә итүдә, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органында, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш) аерым башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 сентябрендәге 20 номерлы карарының 1 пунктының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы белән идарә итүдә, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органында, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш) аерым башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 сентябрендәге 20 номерлы карарының 1 пунктының үз көчен югалтуын танырга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: И.А.Мифтахов